**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

21.09.2022 № 303

**Татарстан Республикасы Президентының «Аерым категориядәге затларның үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү тәртибе турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Аерым категориядәге затларның үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү тәртибе турында» 2014 елның 27 гыйнварындагы 94 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 24 июнендәге 389 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамада «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләренә алмаштырырга;

б) преамбулада «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләренә алмаштырырга;

в) 1 пунктта «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 2 пунктта «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләренә алмаштырырга;

д) Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм аның бәясен билгеләү, сату (түләп алу) һәм аны сатудан алынган акчаны хисапка кертү тәртибе турында нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә):

атамада «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның өченче абзацында «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт вазыйфасын биләүче затларның, хезмәткәрләрнең физик (юридик) затлардан, аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләкләрдән тыш, үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле рәвештә бүләк алырга хакы юк.»;

4 пунктта «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $13^1$ пунктны өстәргә:

«$13^{1.}$ Дәүләт вазыйфасын биләүче заттан, хезмәткәрдән кыйммәтле металлардан һәм (яисә) асылташлардан эшләнгән бүләкне сатып алу турында әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза бирелмәсә яисә әлеге

затлар мондый бүләкне сатып алудан баш тартса, кыйммәтле металлардан һәм (яисә) асылташлардан эшләнгән бүләк вәкаләтле структур бүлекчә тарафыннан «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы каршындагы Россия Федерациясе кыйммәтле металлар һәм асылташлар дәүләт фондын формалаштыру, кыйммәтле металларны һәм асылташларны саклау, тапшыру һәм файдалану буенча дәүләт учреждениесе (Россия Гохран)» федераль казна учреждениесенә Россия Федерациясе кыйммәтле металлар һәм зиннәтле ташлар дәүләт фондына кертү бирү тапшырыла.»;

Нигезләмәгә кушымтаның раслау грифындагы «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфалары башкаруларына бәйле» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алулары турында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерык аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН